КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № 1262

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 октябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1018 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1100 нче; 2021 ел, 24 ноябрь, 1117 нче; 2021 ел, 17 декабрь, 1247 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктның уникенче абзацында «сәүдә-күңел ачу үзәкләренә (комплексларына)» сүзләрен «сәүдә-күңел ачу, күңел ачу үзәкләренә (комплексларына), биналарда урнашкан аттракционнарга» сүзләренә алмаштырырга, «букмекер контораларына» сүзләреннән соң «, компьютер клубларына һәм интернет-клубларга, боулингларга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 пунктчасының икенче абзацында «сәүдә-күңел ачу үзәкләренә (комплексларына)» сүзләрен «сәүдә-күңел ачу, күңел ачу үзәкләренә (комплексларына), биналарда урнашкан аттрак-

ционнарга» сүзләренә алмаштырырга, «букмекер конторaларына» сүзләреннән соң «, компьютер клубларына һәм интернет-клубларга, боулингларга» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының 3 пунктындагы дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2022 елның 11 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин